Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290
==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

27сентябрь 2022 года № 19/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында карарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылуда катнашу турында " 28.10.2019 ел, № 51/2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле 13 нче пунктка өстәргә:**

«13). нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү.»;

**түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктын өстәргә:**

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы _ авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре күрсәтелгән 3 пунктта нотариаль гамәлләр башкарылган очракта нотариаль документларны саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм куллануны тәэмин итә. Җирлек бетерелгән яки муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, бетерелгән яки үзгәртелгән җирле үзидарә органының нотариаль документлары җирле үзидарә органына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru0 Татарстан Республикасы Чүпрәле

муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә ).

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов